| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422050, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2 тел. (84362) 3-21-44 | 422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Шэмэмрдэн авылы, Лермонтов урам, 2 йорт тел. (84362) 3-21-44 |

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 09.11.2020 | № 11 |

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт ечен түләү шартлары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече теркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А. Н.Гәрәев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының
2020 елның 9 ноябре, № 11 карарына

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |
| Депутатлар | 11498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11498 |